**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет «Тумутукского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Тельмана, д.62Б, с. Тумутук
Азнакаевского муниципального района
423316, Тел. (885592) 3-34-42

Электронная почта: Tumut.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б
423316, Тел. (885592) 3-34-42

Электрон почта: Tumut.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» гыйнвар 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Күмү һәм күмү эше турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге карар бирә:

1. 2021 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6 424,98 (алты мең дүрт йөз егерме дүрт сум, 98 тиен) күләмендә, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http// pravo. tatarstan. ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatarstan. ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Э.Х.Гыйләҗева

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге башкарма комитет карарына 1 нче кушымта «29» гыйнвар 2021 № 2

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең хакы**

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 148,98 |
| 2. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 963,00 |
| 3. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 313,00 |
| 4. | **Барлыгы** | **6 424,98** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл жирлеге башкарма комитет карарына 2 нче кушымта «29» гыйнвар 2021 № 2

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең хакы**

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда. |
|---|---|---|
| 1. | Кәфенләү | 841,42 |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 307,00 |
| 3. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 963,56 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1 313,00 |
| **5.** | **Барлыгы** | **6 424,98** |